ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17 август 2020ел № 3995

Башкарма комитетның 2015 елның 24 декабрендәге 7379 номерлы карары белән расланган капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2015 елның 24 декабрендәге 7379 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 9 декабрендәге 6589 номерлы, 2017 елның 9 июнендәге 3530 номерлы, 2017 елның 27 сентябрендәге 5760 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктта «стационар җәмәгать туклануы объектлары карамагында урнаштырылган» сүзләреннән соң «күчмә корылмалар (лотоклар, автокибетләр, автофургоннар, автолавкалар, автоцистерналар, арбалар һәм башка шундый ук объектлар),» сүзләрен өстәргә;

2) 6, 7, 10 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

3) 8 пунктта «демонтажлау» сүзеннән соң «күчерү» сүзен өстәргә;

4) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Объект хуҗасы ачыкланмаган очракта, район хакимиятенең вазыйфаи затлары күрсәтмәнең күчермәсен турыдан-туры объектка урнаштыралар һәм бу хакта күрсәтмә бланкында билгеләп куела һәм өч эш көне эчендә күрсәтмәнең күчермәсен «Челнинские известия» газетасында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәләр.»;

5) 11 пунктның икенче абзацында «һәм аны өч эш көне эчендә Бүлеккә

җибәрә» сүзләре үз көчен югалткан дип танырга;

6) 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Нигезләмәнең 11 пунктында билгеләнгән срок дәвамында объект аның хуҗасы тарафыннан ирекле рәвештә демонтажланмаган очракта, район хакимиятенең вазыйфаи затлары тикшерү актын, объектны урнаштыруның законсыз булу фактын раслый торган документларны һәм күрсәтмәне кабул итеп алу, урнаштыру фактын раслый торган документларны (башка дәлилләрне), шулай ук әлеге нигезләмәнең 3 нче кушымтасы нигезендә, күрсәтмәне үтәмәү турындагы актны теркәп, законсыз урнаштырылган объектны демонтажлау һәм (яки) күчерү турында Башкарма комитет карары проектын әзерләүне гамәлгә ашыралар һәм аны билгеләнгән тәртиптә раслыйлар.»;

7) 25 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25. Объект демонтажланган көннән башлап өч көн эчендә, объектны демонтажлау датасын һәм вакытын, объектны һәм андагы мөлкәтне объект хуҗасына бирү тәртибен күрсәтеп, демонтажлау турындагы мәгълүматны «Челнинские известия» газетасында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны район хакимиятенең вазыйфаи затлары тәэмин итә.»;

8) түбәндәге эчтәлектәге 5 бүлекне өстәргә:

«5. Законсыз урнаштырылган күчмә корылмаларны (лотоклар, автокибетләр, автофургоннар, автолавкалар, автоцистерналар, арбалар һәм башка шундый ук объектлар) күчерү тәртибе

33. Күчмә корылмаларны (алга таба - күчмә сәүдә объекты) законсыз урнаштыру факты билгеләнгәндә, район хакимиятенең вазыйфаи затлары 1 нче кушымтада каралган форма буенча акт төзиләр.

34. Объект ачыклангандa күчмә сәүдә объекты хуҗасы билгеле булган очракта, район хакимиятенең вазыйфаи затлары тарафыннан объект хуҗасына (вәкаләтле вәкилгә) имза куйдырып, 7 нче кушымта нигезендә күчмә сәүдә объектын ирекле рәвештә күчерү турында күрсәтмә тапшырыла.

35. Объект хуҗасы ачыкланмаган очракта, район хакимиятенең вазыйфаи затлары күрсәтмәнең күчермәсен турыдан-туры объектка урнаштыралар һәм бу хакта күрсәтмә бланкында билгеләп куела һәм өч эш көне эчендә күрсәтмәнең күчермәсен «Челнинские известия» газетасында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәләр.

36. Законсыз урнаштырылган күчмә сәүдә объектының хуҗасы, күрсәтмә кулга тапшырылган, почта аша алынган, «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырылган, «Челнинские известия» газетасында бастырып чыгарылган вакыттан башлап өч тәүлек эчендә, үз көче белән һәм үз хисабына күчмә сәүдә объекты законсыз урнаштырылган урынны азат итәргә һәм күчмә сәүдә объекты законсыз урнаштырылган урынны элекке хәленә кайтарырга тиеш.

37. Нигезләмәнең 36 пунктында билгеләнгән срок эчендә күчмә сәүдә объекты мондый объектның хуҗасы тарафыннан ирекле рәвештә күчерелмәсә, район хакимиятенең вазыйфаи затлары бер эш көне эчендә, законсыз урнаштырылган күчмә сәүдә объектын күчерү турында Башкарма комитет карары проектын әзерләүне гамәлгә ашыралар һәм шул ук көнне аны Башкарма

комитетка җибәрәләр.

38. Законсыз урнаштырылган күчмә сәүдә объектын күчерү турында Башкарма комитет карары имзаланган һәм теркәлгән көнне әлеге карар, мондый объектны махсуслаштырылган саклау мәйданчыгына күчерү эшен оештыру өчен, Башкарма комитетның тиешле район хакимиятенә җибәрелә.

39. Күчмә сәүдә объектын күчергәндә андагы мөлкәт, әлеге нигезләмәгә 5 нче кушымтада каралган форма буенча, район хакимиятенең вазыйфаи затлары тарафыннан төзелә торган исемлеккә кертелергә тиеш.

40. Күчерү эшләре, шулай ук төяү-бушату эшләре тиешенчә башкарылмау нәтиҗәсендә күчмә сәүдә объекты хуҗасына китерелгән югалтулар, җитмәү яисә зыян өчен махсуслаштырылган оешма җаваплы.

41. Күчмә сәүдә объектларын кире кайтару Нигезләмәнең 26-27 пунктларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

42. Мондый объектлар махсуслаштырылган саклау мәйданчыгына күчерелгән көннән башлап 30 календарь көн эчендә, Башкарма комитетының тиешле район хакимиятенең вазыйфаи затлары объект хуҗасына 8 нче кушымтада каралган форма буенча белдерү кәгазе җибәрәләр һәм мондый белдерүне «Челнинские известия» газетасында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәләр.

43. Күчмә сәүдә объектларын саклау алты ай дәвамында гамәлгә ашырыла.

44. Күчмә сәүдә объектлары махсуслаштырылган саклау мәйданчыгына күчерелгән көннән башлап алты ай узгач, Башкарма комитет күчмә сәүдә объектын хуҗасыз дип тану һәм аңа муниципаль милек хокукын тану турында судка дәгъва гаризасын әзерләүне гамәлгә ашыра.

45. Күчмә сәүдә объектын хуҗасыз дип тану һәм аңа муниципаль милек хокукын тану турында суд акты үз көченә кергән көннән башлап өч эш көне эчендә, Башкарма комитет билгеләнгән тәртип нигезендә, алга таба мондый мөлкәттән файдалану турында карар кабул итә.»;

8) 1 нче, 2 нче кушымталарда каралганча 7 нче, 8 нче кушымталар өстәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының районнар хакимияте Башлыклары А.И. Кисловка, И.Н. Галимовка, В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 17 августындагы
3995 номерлы карарына
1 нче кушымта

Капиталь төзелеш объекты булмаган
законсыз урнаштырылган объектларны
ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм
саклау тәртибе турында нигезләмәгә
7 нче кушымта

Законсыз урнаштырылган күчмә сәүдә объектын күчерү турында
күрсәтмә

№ _________ «_____» ___________ 20______ ел

Кемгә: ______________________________________________________________
(гражданның (ШЭ) Ф.И.А.и. яисә юридик затның иseме һәм адресы)

_____________________________________________________________________
(күрсәтелә: әлеге күрсәтмә кулга, почта аша тапшырылган, күрсәтмә «Челнинские известия» газетасында бастырып чыгарылган һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырылган)
вакыттан башлап 24 сәгать эчендә

Сезгә ирекле рәвештә үз көчегез белән һәм үз хисабыгызга түбәндәге адрес буенча урнашкан: ____________________________________________________________,
күчмә сәүдә объекты

_____________________________________________________________________,
(күрсәтелә: автокибет, автолавка, автоприцеп, автокафе, изотермик савытлар һәм цистерналар, арбалар, лотоклар һәм сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен башка махсус җайланмалар)
законсыз урнаштырылган урынны азат итәргә, шулай ук күчмә сәүдә объекты урнашкан урынны элекке хәленә кайтарырга кирәк.

Күрсәтмә белән таныштырылды

_____________________________________________________________________.
(вазыйфаи затның имзасы, имзаның расшифровка)

_____________________________________________________________________

Күрсәтмәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:
1) күрсәтмәне алудан һәм аның белән танышу турында имза куюдан сәбәпләр буенча (күрсәтергә) (сәбәпләрен аңлатмыйча) баш тартты;
2) күрсәтмә тапшыру турында белдерү кәгазе белән почта аша җибәреләчәк;
3) объектны законсыз урнаштыруны гамәлгә ашырган зат билгеләнмәгән;
4) күрсәтмә (фотофиксация белән) объектта урнаштырылган.

______________________________________________________________________

(район хакимияте вәкиленең имзасы, имзаның расшифровкасы)

______________________________________________________________________

(вәкаләтле органның адресы, элемтә телефоны)

Башкарма комитетның ________________________________ районы хакимияте Башлыгы
_________________________

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2020 елның 17 августындагы
3995 номерлы карарына
2 нче кушымта

Капиталь төзелеш объекты булмаган
законсыз урнаштырылган объектларны
ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм
саклау тәртибе турында нигезләмәгә
8 нче кушымта

Күчмә сәүдә объекты хуҗасына
___________________________________
___________________________________

Әлеге белдерү кәгазе белән Сезгә, ________________________________ адресы буенча урнашкан саклау мәйданчыгына күчерелгән, Сезнең карамактагы күчмә сәүдә объектын кире кайтару турындагы гариза белән Сез Башкарма комитетка мөрәҗәгать итәргә хокуклы булу турында хәбәр итәбез. Шул максат белән Сезгә түбәндәгеләрне тапшырырга кирәк:

- объектның кемнеке булуын раслый торган документлар;
- объектны күчерүгә һәм саклауга бәйле чыгымнар өчен түләүне раслый торган документлар.

Башкарма комитетның ________________________________ районы хакимияте Башлыгы
_________________________

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева